
# Сынлы сәнгать музеенда (4 нче сыйныфта әдәби уку дәресе)

(Б.Әлменовның иҗаты буенча )

Башкаручы: Татарстан Республикасының Балык Бистәсе районы Зур Мәшләк урта мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Гарипова Фәридә Солтангали кызы


# Сынлы сәнгать музеенда




# Кайсы артык?













# БЕЗ ШУРӘЛЕ ТУРЫНДА НӘРСӘ БЕЛӘБЕЗ?


| БАШТА | АХЫРДА |
| --- | --- |
| ??? | ??? |

# Кайсы артык?











# Рәссам Байназар Әлменов

- 1909 елның 14 августында Самара губернасы Бозаулык өязе (хәзерге Ырынбур өлкәсе, Тоцк районы) Кызыл Мәчет авылында зәркән остасы гаиләсендә туа. 1976 елда Казанда вафат.
- 1930 елда Самарадагы татар-башкорт техникумын, 1934 елда Пенза сәнгать-педагогия техникумын тәмамлый.1934-1935 елларда Куйбышев шәһәрендә «Кызыл-
- армияче» гәзитендә рәссам булып эшли.
- Татарстан китап нәшриятында бизәлеш мөхәррире (1935 елдан), бизәлеш мөхәррририятенең мөдире (1947 елдан).
- Сугыш елларында фашистларга каршы плакатлар яза: «Калдырма!», (1940); «Фашизмның канлы сатраплары», (1941); «Икмәк - фронтка», (1943).
- 1943 елда «Сугыш эпизодлары» дип аталган график рәсемнәре почта открыткалары итеп бастырыла. Конверт тышлары өчен каһарман татарларның портретларын ясый.




# БИЗӘҮЧЕ -РӘССАМ

- 300 дән артык китап бизи. «Идегәй» дастаны һәм татар әдәбияты әсәрләре, «Әлифба»





**Татарстан китап нәшриятының яшь рәссамнары белән (1955)**





**Кыям Миңнибаев, Байназар Әлменов һәм Марк Зарецкий (1975)**






Физминутка



# Г.Тукай әсәрләрен бизәүче

# Легендар татар шәхесләре портретлары








# Б.Әлменов үзе



- Әсәрләре ТР дәүләт сынлы сәнгать музеенда, ТР милли музеенда, Яңа Кырлай авылындагы Габдулла Тукай музей-комплексында,Алабуга шәһәрендәге И. И. Шишкин музей-йортында, кызы Инга Байназар кызы Әлменова гаиләсендә саклана.







# Рәсемгә туры килгән юлларны табып укы

Нәрсә бу? Качкынмы, җенме? Я өрәкме, нәрсә бу?

Коточарлык, бик килешсез, әллә нинди нәрсә бу!

Борыны кәп-кәкре, бөгелгәндер – тәмам кармак кеби;

Төз түгел куллар, аяклар да ботак-тармак кеби.

Ялтырый, ялт-йолт киләдер эчкә баткан күзләре,

Кот очар, күрсәң әгәр, төнлә түгел – көндезләре.

Яп-ялангач, нәп-нәзек, ләкин кеше төсле үзе;

Урта бармак буйлыгы бар маңгаенда мөгезе.

Кәкре түгелдер моның бармаклары – бик төз-төзен,

Тик килешсез – һәрбере дә ярты аршыннан озын.



# Рефлексия

- *Мин белдем...*
- *Кызык булды...*
- *Авыр булды...*
- *...биремнәр үтәдем.*
- *Хәзер мин беләм..*
- *Мин булдырам...*
- *Гаҗәпләндем...*

# Өй эше

- Б.Әлменовның картинасы буенча иҗади эш(сайлап ал!)
- 1) Мин-Шүрәле! (язма эш)
- 2)Шүрәлегә бәяләмә (характеристика)язарга.

# Батырдан үлем дә курка

Асия Миннуллина

